Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл Советы
КАРАРЫ

14 октябрь 2021 ел №27

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Бишмунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районыны «Бишмунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында төзелгән килешү тәртибендә

Бишмунча авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Бишмунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Бишмунча авыл Советы белән расланган «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетына, Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан Бишмунча авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән, вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Бишмунча авылы, Совет урамы, 57 нче а йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 а йорт, Бакчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы"нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Бишмунча авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Бишмунча авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Фазлыев